**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «11» маеннан № 187

**«Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 25 сентябрендәге 406 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация бирү эшен оештыру турында» 2016 елның 12 апрелендәге 20-18\4912 номерлы хатын үтәү йөзеннән, Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 25 сентябрендәге 406 номерлы карары белән расланган (Башкарма комитетның 2014 елның 17 гыйнварындагы 16 номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 299 номерлы карарлары редакциясендә) мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә түбәндәге эчтәлектәге 10.1 пунктын өстәп, үзгәрешләр кертергә:

10.1 «Компенсация билгеләү гаризада күрсәтелгән гариза бирүченең ризалыгы белән, Россия Федерациясе Пенсия фондында булган белешмәләр нигезендә, соңгы 3 айда, гариза бирүченең компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айга кадәр булган 12 айдан алынган мәгълүматлар нигезендә башкарыла»

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **В.Н. Семеняк**